ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д.12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

27 09 2024 г. № 1003

Гражданнар һәм алар белән бергә даими яшәүче гаилә әгъзалары кеременең һәм аларның салым салынырга тиешле мөлкәтләре хакының чик күрсәткечләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 14 статьясы, «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күрсәткечләрен билгеләү методикасы һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм күрсәтелгән законга кушымтада бәян ителгән салым салынырга тиешле мөлкәт хакы турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Гражданнарны аз керемлеләр дип тану турында Карар кабул итү өчен түбәндәге чик күрсәткечләрне билгеләргә:

1.1. Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган уртача айлык җыелма керем күләме – 40 083, 74 сум.

1.2. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакы чиге:

1.2.1. Ялгыз яшәүче кеше өчен – 2 686 428 сум;
1.2.2. Гаилә өчен ике кешедән – 5 372 856,00 сум;
1.2.3. Өч кешедән торган гаилә өчен – 8 059 284,00 сум;
1.2.4. Дүрт кешедән торган гаилә өчен – 10 745 712,00 сум;
1.2.5. Биш кешелек гаилә өчен – 13 432 140,00 сум;
1.2.6. Алты кешелек гаилә өчен – 16 118 568,00 сум;
1.2.7. Җиде кешедән торган гаилә өчен – 18 804 996,00 сум;
1.2.8. Сигез кешедән торган гаилә өчен – 21 491 424 сум;
1.2.9. Тугыз кешедән торган гаилә өчен – 24 177 852 сум;
1.2.10. Ун кешелек гаилә өчен – 26 864 280 сум.

2. «Гражданнар кеременең һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен билгеләү турында» 2022 елның 27 маендагы 135 номерлы Түбән Кама шәһәре Башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.Ф. Булатов